КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 22 август г.Казань № 681

Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар билгеләнгән критерийләр буенча күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатлы булулары турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар билгеләнгән критерийләр буенча күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатлы булулары турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына, Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:

30 көн эчендә социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерийләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү вәкаләтләрен ныгыту өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең күрсәтелгән башкарма органнары турында нигезләмәләргә үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарлары проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен билгели торган административ регламентларны эшләргә һәм расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин